ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАСЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422647, с. Масловка,
ул. Центральная, дом 13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАСЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422647, Масловка авылы,
Центр урамы, 13 нче йорт

Тел.: (84361) 253 55, факс: (84361) 253 55, e-mail:Masl.RS@tatar.ru сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.09.2019г. с. Масловка № 38

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында " 2019 елның 12 мартындагы 21 номерлы карары белән расланган күчемсез милек объектына адрес бирү (үзгәртү, төгәлләштерү, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында»

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Салым салу максатлары өчен бәяләрне билгеләү принципларын камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 18.07.2011 ел, №227-ФЗ Федераль законга, «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне планлаштыру һәм территорияләрне комплексы, тотрыклы үстерүне тәэмин итү буенча документларны әзерләүне, килештерүне һәм раслауны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 03.07.2016 ел, №373-ФЗ Федераль законга таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы 21нче номерлы карары (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Башкарма комитетының 14.06.2019 ел, 29нчы номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Торак бинаны үзгәртеп коруга һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3нче кушымтаның 1.5 пунктында:

а) “адреслаштыру объекты - күчемсез мөлкәтнең бер яки берничә объекты, шул исәптән җир кишәрлекләре, йә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресларны бирү, үзгәртү, юкка чыгару кагыйдәләре белән каралган очракта” җөмләсен «адреслы объект - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адреслар исемлегендә каралган башка объект” җөмләсенә алмаштырырга;»;

б) “планлаштыру структурасы элементы» - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерцияле булмаган дача берләшмәләрен урнаштыру территорияләре” җөмләсен “планлаштыру структурасы элементы-муниципаль районның җирлеге, шәһәр округы яки авылара территориясенең бер өлеше (квартал, микрорайон, район һәм башка шундый элементларны). Планлаштыру структурасы элементлары Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә” җөмләсе белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Масловка авылы, Үзәк урамы, 13 йорт;

- Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы” Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге
башлыгы А.И.Егоров